Совет Старочукалинского
сельского поселения Дрожжановского муниципального
района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Иске Чокалы
авыл җирлеге Советы

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12
ОГРН 1021606556850 ИНН 1617000612

==================================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с. Старые Чукалы

19 мая 2020 года № 56/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (2019 елның 16 декабрендәге үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының 28.10.2009 ел, № 51/1 карары белән расланган Нигезләмәгә, **16 статьяның 3 пунктын** түбәндәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче зат үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына мәгълүмат бирә.

Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасын биләп торучы һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы зат күрсәтелгән мәгълүматларны депутат итеп сайлаганнан соң дүрт ай эчендә, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырганнан яки аның вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыруын туктатканнан соң, шулай ук хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында»2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрне башкарган очракта, һәр ел өчен тапшыра.

Хисап чоры дәвамында мондый килешүләр башкарылмаса, күрсәтелгән зат бу хакта Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итә.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегенең рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Низамутдинов